# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**7 декабрь 2023 ел** **№2**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1000 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 500 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:
   - торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
   - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (Сарлыда юл ремонтына вак таш сатып алу);
   - бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру (чараларны уздыру өчен аппаратура алу);
   - авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (балалар өчен уен аттракционнары сатып алу, МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (ботак турагыч, чапкыч).
3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хаҗиев